**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район
с.Алан-Бексер, ул.Центральная, д.19

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

Тел./факс: +7(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** | **КАРАР**

**13 ноябрь 2023 ел** | **№ 87**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының «Физик затлар милкенә салым турында» 2015 елның 15 октябрендәге 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 15.10.2015 ел, № 7 карарына (Советның 05.05.2018 ел № 129, 20.09.2018 ел № 143, 29.12.2018 ел № 157, 29.11.2022 ел № 67, 19.09.2023 № 81 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 нче пунктның 3.2 пунктчасы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.2 Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә милеккә ия булган Россия Федерациясе физик затларын мөлкәткә салым түләүдән азат итәргә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының интернет челтәрендәге http://vysokaya-gora.tatarstan.ru адресы буенча урнашкан рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина